ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 19.08.2026 1235 КАРАР

**Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибен һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен раслау турында» 2022 елның 5 сентябрендәге 1142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибен һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен раслау турында» 2022 елның 5 сентябрендәге 1142 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның бөтен тексты буенча «йөк ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен тиешле килешләрдә «йөк ташуларны гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. карарның бөтен тексты буенча «таныклык» сүзләрен тиешле килешләрдә «хокук» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. Нигезләмәнең 4 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 4.11 пункты белән тулыландырырга:

«4.11. Пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны гамәлгә ашыру хокукының аерылгысыз өлеше булган маршрут карталары, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә төзелә һәм рәсмиләштерелә, шулай ук мөрәҗәгать итүче гаризасы буенча кәгазь документ рәвешендә бирелергә мөмкин. Вәкаләтле вазифаи затның квалификацияле электрон имзасы булганда маршрут картасының электрон версиясе кәгазь версиясе белән бертигез юридик көчкә ия».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзекләндерү һәм инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче
вазифаларын башкаручы

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00EF64EBB949F1A987030464884AC8DB87
Владелец: Томилин Андрей Александрович
Действителен с 22.12.2025 до 17.03.2027

А.А. Томилин